**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 ноябрь № 843

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 24 март, 178 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктка «әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан» дигән сүзләрдән соң «(әлеге Тәртипнең 2 нче пунктындагы «$б^1$» пунктчасында күрсәтелгән заказчылардан тыш)» дигән сүзләрне өстәргә;

3 нче пунктның «$б^1$» пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле «$3^1$» нче пункт өстәргә:

«$3^1$. Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнары әлеге Тәртипнең 2 нче пунктындагы «$б^1$» пунктчасында күрсәтелгән заказчылар тарафыннан чираттагы финанс елына һәм планлаштырылган чорга (чираттагы финанс елы) түбәндәге нигезләмәләрне исәпкә алып формалаштырыла:

Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алулар планнарын формалаштыралар һәм аларны предприятиегә карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органнарга алар өчен билгеләнгән вакытларда, әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча тапшыралар;

кирәк булганда, сатып алулар планнарын тәгаенлиләр, аларны тәгаенләгәннән һәм предприятиенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын раслаганнан соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда сатып алулар планнарын раслыйлар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\843.doc